| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«26» март 2025ел № 53

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 декабрендәге 202 номерлы «2024, 2025, 2026 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 14 декабрендәге 202 номерлы «2024, 2025, 2026 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025, 2026, 2027 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын раслау турында»;

Б) күрсәтелгән карар белән расланган 2025, 2026, 2027 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның 14 декабрендәге
202 номерлы карарына
(«26» 03 2025 № 53
карар редакциясендә) кушымта

**2025, 2026, 2027 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Кыскасроклы планы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган 2024, 2025, 2026 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның әлеге Кыскасроклы планы (алга таба - ТР Кыскасроклы планы) Россия Федерациясе Торак кодексы, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Татарстан Республикасы Законы) нигезендә, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү, дәүләт ярдәме төрләрен һәм күләмен, капиталь ремонт ясауга муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнелгән.

## II. Кыскасроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыскасроклы планның төп максатлары булып тора:

- Теләче муниципаль районында торак фондын саклау, торгызу һәм сыйфатын арттыру;
- гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру; күп фатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм күрсәтү. Кыскасроклы планның төп бурычлары булып тора:
- халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;
- Кыскасроклы план башкаручыларны сайлап алу буенча ачык һәм гәвами процедураларны эшләү һәм үтәү;
- озак вакытка җитә торган материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлар һәм комплекслы куллану.

Кыскасроклы планны гамәлгә ашыру срогы - 2025, 2026, 2027 еллар.

Кыскасроклы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 2 мең кв. метр булган 4 күпфатирлы йортта 57 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш. Әлеге Кыскасроклы планны үтәүнең планлаштырылган күрсәткечләре Кыскасроклы планга 1 номерлы кушымтада күрсәтелгән.

## III. Кыскасроклы планны үтәүдә катнашучы авыл җирлекләре исемлеге

Кыскасроклы планны үтәүдә катнашучы Теләче муниципаль районы авыл җирлекләре исемлеге мондый җирлекләрнең территориясендә түбәндәгеләрнең булуын исәпкә алып формалаштырылды:

а) Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартлары үтәлгән;

б) Дәүләт торак күзәтчелеге органнары белән Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә муниципаль программаны тормышка ашыруның кыскасрокл ы (еллык) планнары расланган һәм килештерелгән.

Кыскасроклы планны тормышка ашыруда Теләче авыл җирлеге һәм Үзәк авыл җирлеге катнаша.

## IV. Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләме

2025 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре:
Татарстан Республикасы, Теләче районы, Шармаш ав., Школьная ур., 60 й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Фасадны җылыту | кв. метр | 240 |

2025 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре:
Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Дальняя ур., 1а й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау | п. м. | 120 |
| Йорт эчендәге су чыгару системасын ремонтлау | п. м. | 98,5 |

2025 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре: Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 68а й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге салкын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау | пог. метр | 60 |
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | пог. метр | 81 |
| Түбә ремонтлау | кв. метр | 303 |
| Газ белән тәэмин итүнең эчке инженерлык системасын ремонтлау | пог. метр | 60 |
| Фасадны җылыту | кв. метр | 392 |

2026 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре:
Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Молодежная ур., 11в й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | метр | 30 |

2026 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре:
Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 68а й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү системасын ремонтлау | пог. метр | 360 |
| Подъездны ремонтлау | кв. метр | 23 |

2027 елда күпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау күләмнәре:
Татарстан Республикасы, Теләче районы, Теләче ав., Ленин ур., 68а й.

| Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | Эшләр күләме |
|---|---|---|
| Йорт эчендәге электр белән тәэмин итү системасын ремонтлау | пог. метр | 360 |
| Подъездны ремонтлау | кв. метр | 23 |

Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау күләмнәре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы «2024, 2025, 2026 елларда Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны гамәлгә ашыруның кыска сроклы планына кертелгән ремонт төрләре буенча күпфатирлы йортлар реестры» Татарстан Республикасының Кыскаосроклы планына 2 номерлы кушымтада китерелгән.

## V. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыскасроклы планны финанслау чыганаклары булып Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджетлар һәм күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре акчалары тора.

Кыскасроклы план чараларын финанслауның гомуми күләме тәшкил итәчәк

- 2025 ел: 8350441,00 сум, шул исәптән чаралар:

Татарстан Республикасы бюджеты – 6259921,24 сум;
җирле бюджетлар – 152000,00 сум;
күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре – 1938519,76 сум;

- 2026 ел: 1329447,9 сум, шул исәптән чаралар:

Татарстан Республикасы бюджеты – 309692,14 сум;
җирле бюджетлар – 152000,00 сум;
күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре – 867755,76 сум.

- 2027 ел: 1329447,9 сум, шул исәптән акча:

Татарстан Республикасы бюджеты – 309692,14 сум;
җирле бюджетлар – 152000,00 сум;
күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре – 867755,76 сум.

## 2025 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Фасадны җылыту | 4402352,00 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | 543000 |
| Газ белән тәэмин итүнең эчке инженерлык системасын ремонтлау | 199836,00 |
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | 480000,00 |
| Түбә ремонтлау | 2237544,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 339800,00 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 144909,00 |

## 2026 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | 215045,40 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | 284380,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 86773,50 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 27849,00 |

## 2027 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чаралары күләме

| Күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслауга ихтыяж, сум |
|---|---|
| Йорт эчендәге инж. су бүлү системаларын ремонтлау | 215045,40 |
| Йорт эчендәге инж. салкын су бирү системаларын ремонтлау | 284380,00 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 86773,50 |
| Төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру | 27849,00 |

Муниципаль районның Башкарма комитеты күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау эшләрен уздыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп тора; тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру максатларында, Министрлык тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә белешмәләр базасын (шул исәптән күпфатирлы йортлардагы торак һәм торак булмаган урыннар мәйданнары буенча белешмәләр) төзи; Министрлыкка һәм Кыскасроклы планны башка башкаручыларга Фондка хисаплар формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне актуаль хәлдә төзи.

ТМШ, идарәче оешмалар:

- капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләргә ай саен түләүләр ясыйлар;
- капиталь ремонт өчен кертем рәвешендә түләнә торган биналарның милекчеләреннән акча җыялар;
- капиталь ремонт фондын региональ оператор исәбендә формалаштырганда капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәрен региональ оператор счетына күчерәләр;

- һәр милекче буенча исәпләүләр һәм түләү турында мәгълүматны торак фонды объектларын капиталь ремонтлау һәм аларның торышын мониторинглауның дәүләт программасы үтәлешен мониторинглауның Интеграцияләнгән мәгълүмат-аналитика системасына кертәләр, аңа түбәндәге web-адрес буенча кереп була: https://bars-moni f.tatarj-u/monif/;

- капиталь ремонт өчен түләүләр буенча бина милекчеләренең бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрәләр;

- тикшерү актлары, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьлары, башкарылган эшләр актлары килештерәләр;

- региональ оператор белән түләү документларын формалаштыруга һәм айлык түләүләрне тәэмин итүгә һәм региональ оператор счетына капиталь ремонт кертемнәре буенча милекчеләрнең түләүләре керүгә шартнамәләр (килешүләр) төзиләр;

- биналарның милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, кирәкле исемлек һәм хезмәтләр һәм (яки) эшләр күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында тәкъдимнәр һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тапшыралар;

- күп фатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча милекчеләр җыелышларын оештыралар;

- капиталь ремонт объектларына керү мөмкинлеген гамәлгә ашыралар;

- күпфатирлы йортларга вакытында һәм сыйфатлы капиталь ремонт ясауны тикшереп торалар, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны гамәлгә кертү актларын һәм актларын капиталь ремонтлаганнан соң күпфатирлы йортларны файдалануга кабул итүдә катнашалар;

- күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча күпфатирлы йортларны һәм аңа керә торган инженерлык системаларын аварияне эксплуатацияләүнең билгеләнгән гарантия срогыннан ким булмаган гарантия срогын тәэмин итү буенча дефектлы ведомостьлар, проект-смета һәм башкарма документацияне саклыйлар.

Бина милекчеләре:

- тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләмен билгеләү өчен, кимчелекләр ведомостьларын килештерәләр;

- күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тотуда, шулай ук аларны капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән файдалануга кабул итүдә катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

- күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрнең кыска сроклы план һәм подряд килешүендә билгеләнгән срокларда башкарылуын тәэмин итәләр;

- КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

- күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

- күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

- объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

- подряд шартнамәсе белән каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешма:

- күп фатирлы йортларны капиталь ремонтлаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыра;

- башкарылган эшләрне кабул итүдә катнаша, башкарылган эшләр актларын килештерә;

- объектны файдалануга алуда катнаша, объектны файдалануга кабул итү актын килештерә;

- күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җаваплы;

- проект оешмаларыннан проект-смета документларын кабул итә;

- күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча күрсәтелгән хезмәтләрне (яисә) башкарылган эшләрне кабул итү актына кул кую датасыннан 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы затка күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләр турында һәм (яисә) эшләр башкару турында проект, смета документациясенең, шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм, финанс документларыннан тыш, капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документларны тапшыра;

- законнарда каралган техник заказчының башка функцияләрен башкара.

Район массакүләм мәгълүмат чаралары - «Теләче» газетасы массакүләм мәгълүмат чараларында кыскасроклы планны гамәлгә ашыру барышын даими яктыртталар. Кыскасроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.

## VIII. Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкару өчен, подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе

Подрядчы оешмалар региональ оператор тарафыннан сайлап алына.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин